# Мәктәп хәбәрчесе

**№2 (№5) февраль 2019 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


## *23 февраль – Ватанны саклаучылар көне*




***/Укытучы сүзе /***

### *Имтиханнарга әзерлек кайчан башлана?*

Барыбыз да белгәнчә, 21 гасыр таләпләре 20 гасыр белем бирү системасы таләпләреннән нык аерыла. Бүгенге кон уку- укыту системасы һәрдаим үзгәрешләр кичерә: бу – елдан - ел катлаулана барган БДИ, мәҗбүри бирелергә тиешле фәннәр исемлегенең арта баруы дисенме, барысы да укучылар, укытучылар, әти- әниләр өчен психологик яктан зур сынау. Ләкин бу таләпләрне тиешле дәрәҗәдә үтәү, психологик стресс кичермәс өчен нәрсә эшләргә соң? Иң мөһиме, һәр эшне үз вакытында эшләргә өйрәнергәдер, мөгаен, иртәгесе көнгә калдырмаска тырышырга кирәктер. 9 ел, яки 11 ел буена алынган белемнәр бер көндә, бер айда гына бала хәтеренә кереп урнаша торган әйбер түгел. Имтиханнарны уңышлы тапшыру, ул – бары тик системалы әзерлек, өстәмә биремнәр эшләү, өстәмә материал куллана белү, логик фикер йөртергә өйрәнү нәтиҗәсе. Бу процессны йорт салу белән тиңләп идем мин. Бер рәт кирпеч кую – ул бер уку елы, рәтнең яклары – чирекләр, аерым кирпечләр – уку атналары, көннәре, өйрәнелгән темалар. Әгәр кайсыдыр тема, тегe яки бу сәбәпләр аркасында өйрәнелми калса, бу - йорт стенасынын кирпечләре куелмый калган кебек, хәтердә дә буш урыннар калдыра. Димәк, өй эченә җил-яңгыр, кар-буран, салкын керә дигән сүз. Мондый күренеш беркемне дә канәгать калдырмый. Бу үз чиратында, имтиханнарга инде мәктәп бусагасын атлап керүгә әзерләнә башларга кирәк икәнлеген аңлата.

***Руфия Гафиятуллина. V сыйныф җитәкчесе***

## *Мәктәптә бәйрәм чаралары*

23нче февраль – Ватанны саклаучылар көне. Бу батырлар һәм кыюлар көне. Безнең тормышыбызны дошманнар бозмасын өчен бар ир-егетләребез илебез чикләрен саклыйлар. Бу бәйрәмгә багышлап безнең мәктәптә турнир үткәрелде. Егетләребез **Бөркетләр** һәм **Бүреләр** командаларына бүленеп ярыштылар. Бу ике төркем көчләре белән тигез иделәр. Барлыгы 10 уен төре булды: чаңгыда шуу, винтовкадан ату, шакмак ташу, капчык киеп сикерү, туп белән чабу, автомат җыю, идәннән этелү, противогаз киеп йөгерү, аркан тарту һәм башкалар. Һәрбер егет үз көчен ярыш төрләрендә күрсәтергә тырышты. Мәсьәлән, Камалов Илдуска идәннән этелүчеләр арасында тиңнәр булмады, Илсур абый автомат җыюда иң өлгере булып чыкты. Чаңгы ярышында исә Мөхәмәтҗанов Айрат, җилдәй очып, бар көндәшләрен артта калдырды.



Командалар арасындагы көрәш бик җанлы барды. Янда торган кызлар төркеме, укытучы апалары һәр балага көч биреп, ярдәм итәрдәй булып тордылар. Жюри конкурс нәтиҗәләрен теркәп барды. Ләкин... Уен булгач җиңүчесе дә булырга тиеш. Бу уенда Бөркетләр командасы, бары тик 1 очко исәбенә генә булса да, көндәшләреннән өстен чыкты. Егетләр, без сезнең белән горурланабыз!

Бәйрәм чаралары бакча төркемендә дә узды. Балалар бик тырышып әтиләренә бүләкләр әзерләделәр. Кечкенә дусларыбыз өчен иң дулкынландырган һәм мавыктыргыч вакыйга – АК-74 автоматы белән танышу булды. ТИН укытучысы Илдар абый аларга автоматның ничек эшләүен аңлатты, сүтеп-җыеп күрсәтте. Бәйрәмнән барчабыз да канәгать калдык.

**Бәйрәмнән репортажны Әминә Туктамышева һәм Зөлфирә Сафиуллина әзерләде**

## /ТАССР төзелүгә 100 ел /

### Уртак тырышлык белән

Февраль аенда ТАССР төзелүгә 100 ел уңаеннан авыл җирлекләренең иҗат-отчет концертлары булып узды. Безнең мәктәп укучылары да бу эштән читтә калмады. Өлкән апа-абыйлары белән беррәттән, укучыларыбыз Татарстан тарихының төп этапларын сәхнәләштерелгән тамашада оста итеп чыгыш ясадылар.



Кечкенәдән тормыш йөген тартучы бала ролен Галимов Рияз уйнады. Өлкәннәргә булышуны оештырып, Тимур командасын җитәкләгән Сафиуллин Илсур нәни октябрятларны да тәрбияләргә өлгерде. Ветеран әби ролен башкарган Равия апаларын туган көне белән котлап, Морадимов Илсур, Минакова Ләйлә, Нургалиева Ләйләләр җыр-биюле тамаша белән өлкәннәрне хөрмәтләүне оста итеп сәхнәләштерделәр. Әтиле-уллы Разыйм белән Илназ Морадимовлар, читтә калган апалары өчен ата-баба нигезен кадерләп, саклап торулары белән туган җиргә тугрылык хисен бик уңышлы тасвирладылар. Тамашаның йомгаклау өлешендә укучылар бик эчтәлекле күмәк бию башкардылар. Биючеләрнең киемнәре һәм шарлары Татарстан дәүләт символларының төсен чагылдырды.

Бу тамаша тарихны гына түгел, ә туган якка мәхәббәт, төрле милләт вәкилләренең бердәмлеге, авыл кешеләре өчен кайгышатлыкларның уртаклыгын күрсәтте. Мондый зур эчтәлектәге театрлаштырылган тамашаны оештыручы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге хезмәткәре Морадимова Гөлнара Минзакир кызына рәхмәт сүзләре генә әйтәсе килә. Балаларның чыгышларын оештыручы Сафиуллина Алсу һәм Хәйруллина Рузилә апаларына да киләсе эшләрендә уңышлар теләп калабыз.

***Фәнүзә Гафиятуллина.***
***Ана теле һәм әдәбияты укытучысы***

---

## /Котлыйбыз! /



Февраль аенда туган 3 сыйныф укучылары **Минакова Ләйлә, Йосыпов Рәсим** һәм 6 сыйныфтан **Сидоров Романны** туган көннәре белән котлыйбыз. Укуларында яхшы нәтиҗәләр, сәламәт, акыллы булып үсуләрен телибез.

Безнең яраткан, хөрмәткә лаек укытучыбыз – **Хәсәнова Резедә апаны** гомер бәйрәме белән тәбриклибез. Сезгә ныклы сәламәтлек, бәхетле озын гомер телибез. Киләчәктә дә безне математиканың текә үрләрен яуларга әйдәп барырсыз дигән теләктә калабыз.

## / Мәктәп яңалыклары /

Февраль ае укучылар өчен чараларга һәм очрашуларга бай булды. 5 февральдә район эчке эшләр бүлегенең **ПДН** хезмәткәрләре балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү буенча укучылар белән очрашу уздырдылар.

8 февраль көнне Аксубай **универсаль технологияләр техникумы** укытучылары чыгарылыш сыйныф укучылары белән очрашты. Кунаклар укучыларга техникумда бирелә торган белгечлекләр турында сөйләде. Мәктәп тәмамлаганнан соң техникумга укырга килергә чакырды.

13 февраль IX сыйныф укучылары өчен **рус теленнән йомгаклау әңгәмәсе** үткәрелде. Имтихан кылынган 6 укучының барысы да сынауларын уңышлы үтәде.

Шул ук көнне патриотик айлык кысаларында район күләмендә **"Яшь армиячеләр"** көне үткәрелде. Безнең мәктәптән бу оешма сафларына 3 егетебез кабул ителде. Шулардан Камалов Илдус мәктәптән тыш чараларда актив катнашканы өчен грамота белән бүләкләнде. Бу чарада Насыйрова Сара сугышчан бабайлар турында бик уңышлы чыгыш ясады

14 февраль көнне мәктәпнең Туктамышева Әминә, Әхмәтова Нәзирә, Нурматов Халид, Хайруллин Данил составындагы командасы район үзәгендә оештырылган **кышкы туризм** ярышында катнашты.

22 февральдә Аксубай районы башлыгы ярдәмчесе Э.Ж.Крайнова һәм район прокурорының өлкән ярдәмчесе И.Ф.Гусамов VIII-XI нче сыйныф укучылары белән очраштылар. Алар бүгенге көндә актуаль булган **коррупция** һәм ришвәтчелек проблемасына кагылышлы чыгыш ясадылар.



26 февраль көнне мәктәптә Иске Татар Әдәмсуы авылы китапханәчесе Таһирова Равия апа укучылар өчен **"Китап-белем чишмәсе"** дип аталган мавыктыргыч чара оештырды. Башлангыч сыйныф укучылары, әкият геройлары белән берлектә, тылсымлы китаплар иленә сәяхәт ясады.

*/ Чал тарихта эзле без /*

## *Сигезъеллык мәктәп ачылу*

1960 еллар уртасына Түбән Майна һәм Чуаш Майнасы авыллары өчен уртак бер сигезъеллык мәктәп булдыру турында карар кабул ителә. Ләкин мәктәпне ике авылның кайсында урнаштыру мәсьәләсе хәл ителмәгән була. Мәктәпнең яңа бинасын салу 1965 елда сигезъеллык мәктәпне Түбән Майнада ачарга мөмкинлек бирә. Сигезъеллык мәктәп ачылгач, безнең авылга V-VIII нче сыйныфларга Чуаш Майнасы балалары да укырга йөри башлыйлар. (1970 елдан – IV сыйныфка). Ул елларда үзебезнең авылда да балалар саны шактый арта. 1950 еллар уртасыннан 1960 еллар башына чаклы туган балалар саны ел саен егермедән артык тора. Мәктәп ачылган елны барлыгы 185 бала булса, 1970 елга укучылар саны 250 дән артып китә. Мәктәп балаларын урнаштырырга урын җитмәгәнлектән, баштагы дүрт елда укыту ике сменада алып барыла. Бу кимчелекне бетерү өчен тиз арада укыту мәйданнарын арттыру таләп ителә. Шуны күздә тотып, 1966 елда элекеге мәчеттән калган бина сүтелеп, аның агачларыннан башлангыч мәктәп салына. Элеккеге еллар гадәте буенча, байлардан калган өйләр дә мәктәп кирәгенә файдаланыла. Аерым алганда, Латыйпов Хәсәнша бабайның ташпулатында остаханә оештырыла. 1969 елда мәктәпнең сул як канаты төзелеп беткәннән соң укыту бер сменалы режимга күчерелә. 1970 еллар башында төп укыту бинасы бер бүлмәле янкорма исәбенә тагын да киңәйтелә. 1977 елда кирпечтән мәктәпнең ашханә бинасы салына. 1978 елда авылда балалар бакчасы ачылу сәбәпле, башлангыч мәктәп бинасы аның файдалануына тапшырыла. Шулай итеп, 1970 еллар ахырына мәктәп матди яктан заманына күрә уртача дип бәяләнерлек хәлгә китерелә.

Гомумән алганда, сигезъеллык мәктәп ачылуның авыл өчен әһәмияте бик зур. Моңа кадәр чит авылларга йөреп газапланган балалар үз җирендә төпле белем алу мөмкинлеген алдылар. Мәктәптә укытучылар һәм ярдәмче персонал өчен күпсанлы эш урыннары барлыкка килде, авылда зыялыларның киң катлавын булдыруга юл ачылды.

*/Күренекле шәхесләр /*

## *Мөгаллим Туктаровлар гаиләсе*



1917 елгы инкыйлабка кадәрге чорда татар халкында иң зыялы катлауны дин әһелләре тәшкил итсә, совет чоры башлангач бу өлкәдә беренчелек мәктәп укытучыларына күчә. Әле 1920 еллардан ук безнең төбәктә, профессиональ укытучылар буларак, **Мирза һәм Әсма Туктаровлар** гаиләсе таныла.


Мирза Сафа улы Туктаров 1898 елда Иске Татар Әдәмсуы авылында туа. Аның тормыш иптәше Әсма апа 1907 елгы, чыгышы белән Чистай кәләпүшчесе гаиләсеннән. Аларның педагогик эшчәнлеге укытучылар әзерләү курсларын тәмамлаганнан соң башлана. Мирза абый 1930-1932 елларда Түбән Майна мәктәбен җитәкли. Шуннан соң алар гаиләләре белән Югары Майна авылына күченеп китәләр. 1939 елда бу авылда җидееллык мәктәп ачылуда Мирза Туктаровның өлеше зур була. Ветеран укытучы Хәлиулла бабайның: “Әгәр Мирза абый Майна Башына китмәгән булса, ул мәктәп Түбән Майнада ачыласы иде” – дигән сүзләре моңа дәлил булып тора. Бөек Ватан сугышы башлангач Мирза Туктаров сугышка китә һәм 1943 елның 25 февралендә Ленинград өлкәсе Дубовицы авылы янында һәлак була.

Әсма апа Туктарова калган гомерен Югары Майна мәктәбенә багышлый. Татар теле һәм әдәбияты буенча зур белгеч буларак танылa. Сугыштан соңгы елларда безнең авылдан Югары Майнага йөреп укыган укучылар Әсма апаның эшчәнлеген яхшы хәтерлиләр.


Мирза аганың бертуган абыйсы Зыя Туктаров күренекле укытучылардан. 1918-1923 елларда ул Иске Кыязлы мәктәбен җитәкли. Шул ук вакытта авыл советы сәркәтибе вазифасын да башкара. Кыязлыдан киткәннән соң Аксубай волисполком рәисе булып эшли. 1930 еллар башында Зыя Туктаров Чистай педагогия училищесында завуч итеп билгеләнә. 1938 елда вафат булганчыга чаклы шушы вазифаны башкара. (Рәсемдә – Туктаров Мирза, 1927 ел).

## *Шахмат мәсьәләләре*


*/ Күңелле тәнәфес/*



1. Аклар башлап, 3 йөрештә мат куя



2. Аклар башлап, 4 йөрештә мат куя



3. Аклар башлап, 5 йөрештә мат куя

***/ Безнең уңышлар /***



## ***Фәнни конференцияләр***

Быел безнең мәктәп беренче тапкыр “Россия патриотларын үстерәбез” Республика фәнни-гамәли конференциясендә катнашты. 26 февраль көнне башкалабыз Казанда узган бу чарада 8 сыйныф укучысы **Насыйрова Сара** конкурс эше һәм чыгышы өчен ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының II дәрәҗә дипломы белән бүләкләнде. (Укытучысы **Сафиуллин Илдар Хәбибулла улы**).

28 февраль көнне район үзәгендә уздырылган мәктәп укучыларының физика һәм математика буенча “Тикшерәбез. Проектлаштырабыз” дип аталган фәнни-гамәли конференциясендә 7 сыйныф укучысы **Туктамышева Әминә** “Ташламалар. Алар кемгә файдалы?” дип аталган эзләнү эше белән III урынны алды. (Укытучысы **Хәсәнова Резидә Хәсән кызы**).

## ***Спорт ярышлары***

2 февраль көнне көрәшче егетләребез **татарча көрәш** буенча Норлат районы беренчелегенә якташ сугышчы-интернационалист М.Бакиров призына уздырылган ярышта катнаштылар. Нәтиҗәдә **Камалов Илдус** – I, **Нурматов Халит** – III урыннарны яуладылар. (Остазлары –**Камалов Ильһам Илгизәр улы**)

Шул ук көнне шахматчы егетләребез әлеге спорт төре буенча да мәктәп данын якладылар. Социалистик хезмәт Герое М.А.Михеев хөрмәтенә уздырылган **шашка-шахмат** буенча район турнирында 4 сыйныф укучысы **Хәйруллин Айназ** – I, 7 сыйныфтан **Хәйруллин Данил** – II, 6 сыйныфтан **Нурматов Муса** – III урыннарны алып кайттылар.

## ***Дәрестән тыш эшчәнлек***

Укучыларыбыз кул эшләрендә дә сынатмады. Ай башында узган **“Җирдә синең эзең”** дип аталган район конкурсының “Гадәти булмаган эшләнмә” номинациясендә **Сафиуллина Зөлфирә** – I, **Туктамышева Әминә** – II урыннарны яуладылар. (Остазлары –**Хәйруллина Рузилә Әдһәм кызы**) Рәсем номинациясендә **Насыйрова Сарага** I урын, **Әхмәтҗанова Лилиягә** II урын бирелде. (Остазлары – **Зарипова Зөлфия Дамир кызы**)

Туган телләр айлыгы кысаларында, Театр елы уңаеннан 27 февраль көнне узган **“Театр сәнгате”** район конкурсында укучыларыбыз зур җиңү яулады. Жюри әгъзаларын таң калдырып уйнаучылар 11 сыйныф укучылары **Мөхәммәтҗанов Айрат** белән **Мәгыйзов Ильфир**, 9 сыйныфтан **Морадимов Илназ** булды. Мәктәп труппасы I дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. (Укытучылары – **Нәҗметдинова Раушания Рөстәм кызы**).

## ***Күзәтү***

Табигатьне күзәткәнегез бармы? Күңел күзегез белән дим? Көннәр язгы якка авышкан мәлдә борынны ярып керә торган саф һава үзеннән үзе урамга чакыра. Кояш нурлары тәрәзә пыялаларын каршылыксыз үтеп керә дә, идәнгә сузылып ята. Аннан диварларга үрмәли, гөлләргә куна. Бераздан күңелләрне иләсләндереп җанда әллә нинди хыяллар тудыра, өмет өсти. Тәрәзәгә килеп кояш белән якыннан торып “аралашырга” да өлгермисең, үзең дә сизми урамга атыласың.



Табигатьтә чынлап торып яз башлана. Түбәләрдән ашыга-ашыга тамчылар җиргә омтыла. Тамчы үзенә юл ярырлык хәл туплый да, гөрләвеккә кушылып Каенлыкка ашыга. Ә Каенлык берзаман күкрәк киерерлек көч җыяр да, эре-эре атлап Чирмешәнгә ашыгыр. Чирмешән дә хәзер зур эшкә җыенгандай уфыра башлар. Кышын салкыннан посып яткан калын бозын җимерер дә, аларны барлык көченә Биләр ягына куып китәр. Басулар да кардан арынырга, тынын буып яткан авырлыктан котылып, тирән итеп сулыш алырга омтыла. Аларның зур, җаваплы эшкә әзерләнгән мәле... Икмәк үстерү бурычын үтисе бар...

Табигатьнең генә түгел, мәктәпнең дә нәкъ басу-кырлар кебек олы мәшәкатькә чумган бер дулкынландыргыч вакыты. Безнең дә олы юлга чыгар сукмакларны барлый торган чак. Имтиханнарны уңышлы тапшырасы бар. Яз кояшы йөрәкләргә көч, башыбызга белем өстәсен иде.

**Нәзилә Галимова, 11 сыйныф укучысы**

***/ Укучылар иҗаты /***

## ***Авылым табигате***

Авылымның табигате
Әсир итә һәркемне.
Һәркайдан сагынып кайтам
Ямьле Чирмешәнемне.

Рәхәтләнеп уйнап үсәм
Ямь-яшел әрәмәдә.
Чишмәсеннән сихәт алып
Тау шуам Чәчәбидә.

Хозурланып аккош йөзә
Җәен Сәет күлендә,
Утлап йөри атлары
Шалканат чирәмендә.

Төнбоеклы тын күлдә
Дуслар балык тоталар.
Мунчала күлләрендә
Бал җыя умарталар.

**Самат Гафиятуллин**
**5 сыйныф укучысы**


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина, Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина, Рузилә Мөхәмматова
Сара Насыйрова